СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

30.04.2026 № 9/7

На № ________ от ______________

**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2021 елның 14 декабрендәге 15/7 номерлы карары белән кабул ителгән Тукай муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы уставы нигезендә муниципаль район Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2021 елның 14 декабрендәге 15/7 номерлы карары (24.04.23 №32/9, 30.06.2025 №59/1 карарлар редакциясендә) белән кабул ителгән Тукай муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 1.2 пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль торак контроле предметы булып юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең һәм гражданнарның (алга таба – контрольдәге затларның) торак законнары, энергияне сак тоту турында һәм муниципаль торак фондына карата, аның милек формасына бәйсез рәвештә, энергетик нәтиҗәлелекне күтәрү хакында законнарда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне үтәү тора:».

1.2. 1.2 пунктының 9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар, күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы затлар, региональ операторлар, төзүчеләр, күпфатирлы йорт белән турыдан-туры идарә итүне гамәлгә ашыручы күпфатирлы йорттагы биналар милекчеләре белән күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту һәм (яки) ремонт эшләрен башкару буенча хезмәтләр күрсәтү шартнамәләре төзелгән затлар, күпфатирлы йортта мондый бина милекчеләренә торак-коммуналь хуҗалык системасында мәгълүмат урнаштыру хокукы бирелгән затлар тарафыннан торак-коммуналь хуҗалык системасында мәгълүмат урнаштыру тәртибенә таләпләр;».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм

Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (http:tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет Рәисе К.Р. Нәҗмиев